**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 45 Семейного кодекса Республики Татарстан и статьи 3 и 14 Закона Республики Татарстан «Об образовании»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 сентября 2021 года

**Статья 1**

Внести в часть $2^1$ статьи 45 Семейного кодекса Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 12 (II часть); 2011, № 9 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 60 (часть I); 2020, № 26 (часть I); 2021, № 36 (часть I) изменение, изложив ее в следующей редакции:

«$2^1$. Ребенок имеет право преимущественного приема на обучение по основным общеобразовательным программам дошкольного образования и начального общего образования в государственную или муниципальную образовательную организацию, в которой обучаются его полнородные и неполнородные брат и (или) сестра.».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 3 (часть I), № 40 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 54 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 26 (часть I), № 57 (часть I); 2021, № 36 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте $15^{3}$ части 2 статьи 3 слова «сторон договора о целевом обучении» заменить словами «заказчика целевого обучения»;

2) часть $2^{1}$ статьи 14 изложить в следующей редакции:

«$2^{1}$. Ребенок имеет право преимущественного приема на обучение по основным общеобразовательным программам дошкольного образования и начального общего образования в государственную или муниципальную образовательную организацию, в которой обучаются его полнородные и неполнородные брат и (или) сестра.».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
04 октября 2021 года
№ 74-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясындагы $2^{1}$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$2^{1}$. Бала бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.».

**2 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге $15^{3}$ пунктында «максатчан укыту турындагы шартнамәнең якларын» сүзләрен «максатчан укытуга заказ бирүчене» сүзләренә алмаштырырга;

2) 14 статьяның $2^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Бала бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белемнең һәм башлангыч гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 74-ТРЗ